# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№2** **11.11.2022 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Чемодур авыл җирлеге составына керүче
Чемодур авылында 2023 елда гражданнарның үзара
салымын кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлегендә гражданнар җыены

**Карар чыгара:**

1.2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, 1 нче группа, 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гаиләләрендә махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән, түләүне бер тапкыр киметеп, аны өчен 250 сум күләмендә үзара салым кетергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юнәлдерергә:
- «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел», «Авыл көне» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукция сатып алу;
- Чемодурово авылы территориясендә үлән чабу, чүп-чар җыю хезмәтләре;
- тракторчы хезмәтенә түләү;
-Трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- җиһазлар сатып алу;
- Балалар мәйданчыкларын ремонтлау һәм буяу;
- Чемодурово авылы мәдәният йорты өчен сәхнә костюмнары сатып алу;
- Чемодурово авылы юлларына вак таш җәю.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштыру түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru һәм Чемодурово авылы, Үзәк урамы , 4А йорт , Молодежная урамы, 20А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чемодурово авыл жирлеге башлыгы Н.Б.Котельникова